СОВЕТ
НАЛАСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Вахитова, д. 64, с.Наласа,
Арский муниципальный район, 422018

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАЛАСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
М.Вахитов урамы, 64 йорт, Наласа авылы,
Арча муниципаль районы, 422018

Тел. (84366)50-2-25, факс (84366)50-2-25. E-mail: Nalas.Ars@tatar.ru

“09” октябрь 2019 ел № 92

## Наласа авыл җирлеге Советы

## КАРАРЫ

### Наласа авыл җирлеге
### Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

“Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Наласа авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга яраклаштыру максатынннан, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясына таянып, Наласа авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2014 елның 27 октябрендәге 73 номерлы Наласа авыл җирлеге Советы карары белән расланган (2015 елның 30 июнендәге 92нче, 2015 елның 26 октябрендәге 7/1 нчы, 2016 елның 1 ноябрендәге 26нче, 2017 елның 11 маендагы 34нче, 2018 елның 8 маендагы 53нче, 2018 елның 7 сентябрендәге 56нче номерлы үзгәрешләр белән) Наласа авыл җирлеге Советы Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне расларга:

**1) 5 статьяда:**

**-1 нче өлешнең 14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«14) каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым җыю), транспорт белән чыгару эшчәнлеген оештыруда катнашу;»;

**-1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 20 пункт өстәргә:**

«20) Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә үзирекле төзелгән корылманы сүтү, үзирекле төзелгән корылманы сүтү яки аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карар кабул итү;»

**2) 6 статьяны түбәндәге редакциядә бирергә:**

«6 статья. Җирле үзидарә органнарының җирлекләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре белән бәйле булмаган мәсьәләләрне хәл итүгә хокуклары

1. Җирлекнең җирле үзидарә органнары түбәндәге хокукка ия:

1) Җирлек музейлары булдыру;

2) Җирлектә нотариус булмаган очракта, законнарда каралган нотариаль гамәлләр кылу;

3) опека һәм попечительлек эшчәнлеген тормышка ашыруда катнашу;

4) Җирлек территориясендә җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын тормышка ашыру белән бәйле эшчәнлекне башкару өчен шартлар тудыру;

5) Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм Җирлек территориясендә милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге чараларны тормышка ашыруга ярдәм итү;

6) Җирлек территориясендә урнашкан муниципаль предприятие һәм учреждениеләрдә мобилизация әзерлеге буенча чараларны оештыруда һәм тормышка ашыруда катнашу;

7) муниципаль янгын сагын булдыру;

8) туризмны үстерү өчен шартлар тудыру;

9) кеше хокукларын тәэмин итүгә җәмәгать контролен гамәлгә ашыручы иҗтимагый күзәтчелек комиссияләренә һәм мәҗбүри тоту урыннарында булган затларга ярдәм күрсәтү;

10) Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында" 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук гомумроссия инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре төзегән оешмаларга ярдәм күрсәтү;

11) Торак законнары нигезендә социаль файдаланудагы торак фондының торакка наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан гражданнарга торак бирү;

12) Җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннарга карата гамәлләр кылу эшчәнлеген башкару;

13) "Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында" 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру;

14) инвалидлар, физик мөмкинлекләре чикләнгән затларга адаптив физик культура һәм адаптив спорт үсешенә ярдәм итү.

15) “Кулланучылар хокукларын яклау турында” 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 нче номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру.

2. Җирлекнең җирле үзидарә органнары, Федераль законнар белән каралган очракларда, әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән мәсьәләләрне хәл итәргә, башка дәүләт вәкаләтләрен (“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы буенча бирелмәгән) тормышка ашыруда катнашырга хокуклы, шулай ук башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә карамаган һәм федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән алар вәкаләтләреннән алынмаган башка мәсьәләләрне хәл итәргә, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелгән бюджетара

трансфертлардан гайре,  өстәмә нормативлар буенча салым керемнәрен җирлек бюджеты керемнәре исәбенә хәл итәргә хокуклы.»

**3) 17 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«3. Территория буенча иҗтимагый үзидарә гамәлгә ашырыла торган территория чикләре, җирлек Советы тарафыннан әлеге территориядә яшәүче халык тәкъдиме буенча, җирлек Советы тарафыннан расланган  территория буенча иҗтимагый үзидарә турында Нигезләмә белән билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

**4) 20 статьяны түбәндәге редакциядә бирергә:**

“20 статья. Ачык тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча муниципаль норматив хокукый актлар проектлары буенча фикер алышу өчен җирлек Советы, җирлек Башлыгы катнашында ачык тыңлаулар үткәрелергә мөмкин.

2. Ачык тыңлаулар халык, җирлек Советы яки җирлек Башлыгы, башкарма комитет җитәкчесе инициативасы буенча үткәрелә, Халык яки җирлек Советы инициативасы белән үткәрелә торган Ачык тыңлаулар җирлек Советы тарафыннан, ә җирлек Башлыгы, башкарма комитет җитәкчесе инициативасы белән үткәрелә торганы- җирлек Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

3. Ачык тыңлауларга чыгарылырга тиешле мәсьәләләр:

1) Җирлек уставы проекты, шулай ук әлеге уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль норматив хокукый акт проекты, муниципаль берәмлек Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе нигезләмәләрен, әлеге уставны  норматив хокукый актларга туры китерү максатларында төгәл яңадан торгызу рәвешендәге үзгәрешләр кертелүдән тыш;

2) Җирлек бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турында хисап;

3) Җирлекнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясе проекты;

4) Җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә, муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору өчен  муниципаль берәмлек халкының ризалыгын алу тавыш бирү юлы яисә халык җыеннары белән таләп ителгән очраклардан тыш.

4. Ачык тыңлаулар уздыру турындагы карар, гамәлдәге законнарда башкача каралмаган булса, тиешле орган яисә муниципаль норматив хокукый акт проектын Җирлекнең вазыйфаи заты карап тикшергәнгә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

5. Уздыру вакыты һәм урыны күрсәтелгән ачык тыңлаулар уздыру турындагы карар һәм ачык тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проекты, гамәлдәге законнарда башкача каралмаган булса, ачык тыңлаулар үткәреләсе көнгә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш.

6. Ачык тыңлаулар үткәрү турында карар басылып чыккан көннән алып һәм аларны уздыру көненә кадәр Җирлек халкы җирлек Башлыгына ачык

тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, шул исәптән муниципаль норматив хокукый акт проектына төзәтмәләр һәм башка тәкъдимнәр җибәрергә хокуклы. Җирлек Башлыгы килгән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерүне оештыра. Күрсәтелгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр ачык тыңлауларда катнашучылар игътибарына җиткерелә.

7. Ачык тыңлаулар, гамәлдәге законнарда башкасы каралмаган булса, муниципаль норматив хокукый акт проекты каралган көнгә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча үткәрелә. Ачык тыңлаулар белгечләрне, экспертларны, кызыксынган затларны чакыру белән үткәрелә. Ачык тыңлауларда Җирлекнең теләсә кайсы кешесе катнашырга хокуклы.

8. Ачык тыңлаулар уздыру йомгаклары буенча муниципаль норматив хокукый акт проектын ачык тыңлауларга кабул итү вәкаләтләренә кертелгән җирле үзидарә органнары һәм Җирлекнең вазыйфаи затлары тарафыннан мәҗбүри каралырга тиешле тәкъдимнәр кабул ителә.

9. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре, кабул ителгән карарларның дәлилләнгән нигезләнүен дә кертеп, ачык тыңлаулар үткәрелгәннән соң 5 көннән дә соңга калмыйча басылып чыгарга (игълан ителергә) тиеш.

10. Ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе җирлек Советы карары белән расланган Ачык тыңлаулар турындагы Нигезләмә белән билгеләнә.

11. Әлеге статьяда күрсәтелгән сроклар, әгәр гамәлдәге законнарда Ачык тыңлаулар өчен каралган башка сроклар билгеләнмәгән булса кулланыла.

12. Генераль план проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне ызанлау проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән документларның берсенә үзгәрешләр кертү каралган проектлар, җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын файдалануга шартлы рәвештә рөхсәт бирү турындагы карар проектлары, капиталь төзелеш объектларын үзгәртеп кору, рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең расланган кагыйдәләре булмаган очракта, җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен шундый икенче төргә үзгәртү буенча, шәһәр төзелеше эшчәнлеге законнары нигезләмәләренә таянып, оештыру тәртибе һәм үткәрүе җирлек Советы карары белән билгеләнгән җәмәгать фикер алышулары яки ачык тыңлаулар үткәрелә”.

**5) 23 статьяны түбәндәге редакциядә бирергә:**

“23 статья. Халык җыены

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда, халык җыены үткәрелергә мөмкин:

1) торак пункт территориясен башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертүне үз эченә алган күрсәтелгән торак пункт кергән Җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча;

2) Җирлек составына керүче торак пунктта әлеге торак пункт территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча;

3) авыл торак пунктында авыл җирлеге старостасы кандидатурасын тәкъдим итү, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;

4) авыл торак пунктында халык җыены, шулай ук муниципаль хезмәт турында Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс үткәргәндә конкурс комиссиясе составына кандидатуралар күрсәтү максатларында үткәрелергә мөмкин.

2. Халык җыены торак пунктта яки җирлектә сайлау хокукына ия булган кешеләрнең яртысыннан артыгы катнашканда хокукка ия. Әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булган яртысыннан артыгы бер үк вакытта катнашу мөмкинлеге булмаган очракта, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге торак пунктларында халык җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә белән расланган әлеге торак пункт кергән муниципаль берәмлекнең уставы нигезендә, халык җыены, халык җыенын үткәрү турында карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган вакыт эчендә, этаплап уздырыла. Шул ук вакытта, элек халык җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә киләсе этапларда катнашмый. Җыенда катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, халык җыены карары кабул ителгән дип санала.”

**6) 30 статьяны түбәндәге редакциядә бирергә:**

**«30 статья. Җирлек Советы депутаты статусы**

1. Җирлек Советы депутаты вәкаләтләре аны сайлаган көннән башлана һәм яңа чакырылыш Җирлек Советы эшли башлаган көннән туктатыла.

2. Җирлек Советы депутаты, әлеге Уставта билгеләнгән очраклардан тыш, азат ителмәгән нигездә, депутат эшчәнлеген төп эш урыны буенча эшчәнлек һәм хезмәт вазыйфаларын башкару белән бергә алып бара.

3. Җирлек Советы депутаты статусы белән бәйле чикләүләр федераль законнар белән билгеләнә.

4. Җирлек Советы депутатына Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав, Җирлек Советы карарлары нигезендә үз вәкаләтләрен каршылыксыз гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин ителә.

5. Җирлек Советы депутаты Җирлек Советы тарафыннан расланган депутат этикасы кагыйдәләрен, шул исәптән депутатның түбәндәге бурычларын үз эченә алган кагыйдәләрен үтәргә тиеш:

1) шәхсән үзенә яисә якын туганнарына кагылышлы мәсьәләләрне хәл иткәндә җирле үзидарә органнары, оешмалар, вазыйфаи затлар, муниципаль хезмәткәрләр һәм гражданнар эшчәнлегенә йогынты ясау өчен депутат статусыннан файдаланмаска;

2) үз-үзен тотышы депутат вазыйфаларын объектив башкаруда шик уятырлык хәлләрдән тыелырга, шулай ук абруена яисә Җирлек Советы авторитетына зыян китерерлек низаглы хәлләрдән качарга;

3) мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу куркынычы булганда - шәхси кызыксынуы депутат вазыйфаларын объектив үтәүгә йогынты ясый яки тәэсир итә ала торган хәл туганда, - бу хакта Җирлек Советына хәбәр итәргә һәм әлеге

мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмауга яки җайга салуга юнәлтелгән карарын үтәргә;

4) Җирлек Советында билгеләнгән халык алдында чыгыш ясау кагыйдәләрен үтәргә;

5) депутат эшчәнлеге белән бәйле булмаган максатларда, Федераль закон нигезендә конфиденциаль характердагы белешмәләргә кертелгән, депутат вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә билгеле булган мәгълүматны игълан итмәскә һәм файдаланмаска;

6) депутат вазыйфаларын үтәүгә бәйле рәвештә физик һәм юридик затлардан (бүләкләр, акчалата бүләк, ссудалар, хезмәт күрсәтү, күңел ачу, ял итү, транспорт чыгымнары өчен түләү һәм башка бүләкләүләр) бүләкләр алмаска.

6. Үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы Җирлек Советы депутаты хокуклы түгел:

1) шәхсән яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлеклек белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы яки коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советы идарәсендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, сәяси партиядә, профсоюзда, билгеләнгән тәртиптә теркәлгән катнашудан, башка иҗтимагый оешма, торак, гараж кооперативларында, күчемсез милек хуҗалары ширкәтләрендә, съездда (конференциядә) яки гомуми җыелышта катнашудан тыш), Россия Федерациясе Президенты яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә коллегиаль орган эшчәнлегендә түләүсез нигездә катнашудан тыш, муниципаль берәмлек тарафыннан муниципаль милектә булган оешманы яки идарә итүне гамәлгә куючы (устав капиталында катнашу өлешләре) вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә кую тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү; федераль законнарда каралган башка очракларда;

2) мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗат эшчәнлегеннән тыш, бүтән түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта мөгаллимлек, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, бары тик чит илләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар хисабына гына финанслана алмый;

3) Әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яки күзәтчелек советлары, чит ил коммерциячел һәм хөкүмәтнеке булмаган оешмаларына һәм аларның Россия Федерациясе территориясендәге структур бүлекчәләре составына керергә.

Даими нигездә вәкаләтләр башкаручы депутат гражданлык, административ яки җинаять эше яки административ хокук бозу турындагы эш буенча яклаучы яки вәкил (законлы вәкиллек очракларыннан тыш) сыйфатында катнаша алмый.

Җирлек Советы депутатлары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге Устав белән билгеләнә.

7. Җирлек Советы депутаты “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 нче декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәргә һәм вазыйфаларны башкарырга тиеш.

8. Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы Премьер-министры) карары буенча үткәрелә.

9. Әлеге статьяның 7.2 өлеше нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, "Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм ия булу, акчалалар һәм кыйммәтле әйберләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында” 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законнарда билгеләнгән чикләү һәм тыюларны үтәмәү фактлары ачыкланганда, Татарстан Республикасы Президенты (Татарстан Республикасы Премьер-министры) депутатның, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә күрсәтелгән затларга карата тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә судка бүтән җаваплылык чараларын куллану турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

10. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында белешмәләр "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җирле үзидарә органнарының рәсми сайтларында урнаштырыла һәм (яки), муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә, массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирелә.»

**7) 49 статьяны түбәндәге редакциядә бирергә:**

«49 статья. Башкарма комитет вәкаләтләре

1. Җирлекнең Башкарма комитеты вәкаләтләре:

1) планлаштыру, бюджет, финанслар һәм исәпкә алу өлкәсендә:

- Җирлек бюджеты проектын эшли;

- Җирлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясен эшләүне тәэмин итә;

- Җирлек бюджетының үтәлешен оештыра, Җирлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясе һәм планнарының үтәлешен оештыра;

- бюджет үтәлеше, Җирлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясе үтәлеше турында хисаплар әзерләүне тәэмин итә;

-"Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында" 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законда каралган стратегик планлаштыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;

- Җирлек икътисады һәм социаль өлкәсенең торышын характерлый торган статистик күрсәткечләрне җыюны һәм әлеге мәгълүматларны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына тапшыруны оештыра;

2) Җирлек территориясендәге муниципаль милек белән идарә итү, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләр өлкәсендә:

- Җирлек территориясендәге муниципаль милектәге мөлкәт белән идарә итә, муниципаль милек объектларын булдыру, сатып алу, куллану, эш итү һәм арендага бирү мәсьәләләрен хәл итә;

- Җирлек Советы карары белән билгеләнгән очракларда, муниципаль милекне алу, шул исәптән аны хосусыйлаштыру турында тәкъдимнәр әзерли һәм Җирлек Советы раславына кертә;

- муниципаль милектә булмаган предприятиеләр, оешмалар белән Җирлекнең икътисади һәм социаль үсешендә хезмәттәшлек турында килешүләр төзи; Җирлек территориясендә халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә төрле милек формасындагы предприятиеләр төзүгә булышлык итә;

- Җирлек Советы билгеләгән тәртип нигезендә муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр булдыра, аларның эшчәнлек максатларын, шартларын һәм тәртибен билгели, уставларын раслый, муниципаль казна учреждениеләрен финанслауны тәэмин итә, муниципаль учреждениеләрне һәм предприятиеләрне үзгәртеп кору һәм бетерү мәсьәләләрен хәл итә, контракт нигезендә аларның җитәкчеләрен билгели һәм вазыйфаларыннан азат итә;

- муниципаль казна учреждениеләре эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүне һәм бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан муниципаль йөкләмәне финанс белән тәэмин итүне гамәлгә ашыра, шулай ук муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыра;

- кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен шартлар тудыра;

- әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә һәм муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан башкарыла торган эшләргә тарифлар билгели;

3) авыл хуҗалыгын һәм эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә:

- авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарын киңәйтү өчен шартлар тудыра;

- кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен шартлар тудыра;

4) халыкка торак-коммуналь, көнкүреш, сәүдә һәм башка хезмәт күрсәтү өлкәсендә:

- халыкны җәмәгать тукланууы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра; базар һәм ярминкәләр оештыра;

- социаль файдаланудагы торак фондының торакка наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан гражданнарга торак бирә;

- халыкның ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра;

- Җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыра, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыра;

- җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм тормышка ашыра;

-җирлек халкының массакүләм ял итүе өчен шартлар тудыра һәм халыкның массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыра, гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына керә алуын тәэмин итә;

- энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә муниципаль программаларны гамәлгә ашыра, муниципаль берәмлек чикләрендә муниципаль торак фонды тәшкил иткән күпфатирлы йортларга энергетика тикшерүләре үткәрүне оештыра, энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында законнарда каралган башка чаралар оештыра һәм үткәрә;

- җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннарга карата гамәлләр кылу буенча эшчәнлек алып бара;

5) төзекләндерү өлкәсендә:

-каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм транспорт белән чыгару эшчәнлеген оештыруда катнаша;

- Җирлекне төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тота, Җирлек территориясен төзекләндерү буенча эшчәнлекне (урамнарны яктырту, территорияләрне яшелләндерү, урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләр кую, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тоту) оештыра;

-адреслау объектларына адреслар бирә, адресларны үзгәртә, юкка чыгара, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, төбәк һәм муниципальара, муниципаль районның җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш), җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына, мондый атамаларны үзгәртә, юкка чыгара, мәгълүматны дәүләт адреслар реестрында урнаштыра;

- Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә үзирекле корылманы сүтү, үзирекле корылманы сүтү яки аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карар кабул итә;

6) гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклау, законлылыкны тәэмин итү, халыкны һәм территорияне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә:

- Җирлек территориясендә законнарның, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары актларының үтәлешен, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен саклауны тәэмин итә;

- җирле үзидарә хокукларын бозучы дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт вазыйфаи затлары, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар актларына билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән судта яки арбитраж судта шикаять бирә;

- Җирлектәге торак пункт чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын үткәрүне тәэмин итә;

- җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә, халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыруда ярдәм күрсәтә;

7) мәдәният, спорт һәм балалар һәм яшьләр белән эшләү өлкәсендә:

- Җирлек территориясендә урнашкан Җирлек милкендәге мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклап калу, алардан файдалану һәм халыкка якынайту, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклауны тәэмин итә;

- җирле традицяле халык сәнгате иҗатын үстерү, Җирлектә халык сәнгатен саклау, торгызу һәм үстерү өчен шартлар тудыра;

- Җирлек территориясендә урнашкан муниципаль музейларны карап тотуны тәэмин итә;

- балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыра һәм тормышка ашыра.

8) федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен үтәү өлкәсендә:

- федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

-дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган матди чараларның исәбен алып бара һәм алардан тиешлечә файдалануны тәэмин итә;

- тиешле федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисап бирә;

- Җирлек Советы карарлары нигезендә үзләренә тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен җирле үзидарә органнары карамагында булган матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан өстәмә файдалануны тәэмин итә;

9) башка вәкаләтләр:

- Җирлек ихтыяҗлары өчен ясалма җир кишәрлекләре булдыру өчен кирәкле эшләрне башкаруны тәэмин итә, 2011 елның 19 июлендәге 246-ФЗ номерлы “Федераль милектә булган су объектларында төзелгән ясалма җир кишәрлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында”гы Федераль закон нигезендә ясалма җир участогы ясау турында килешү төзү хокукына ачык аукцион үткәрүне тәэмин итә;

- Җирлек Башлыгы эшчәнлеген оештыру, хокукый, мәгълүмати, матди-техник һәм башка яктан тәэмин итүне башкара;

- Җирлекнең архив фондларын формалаштыруны тәэмин итә;

- әлеге Уставның 5 статьясындагы 1 өлешенең 8-10, 17 һәм 20 пунктларында каралган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү максатларында, гражданнарны Җирлек өчен әһәмиятле булган социаль эшләрне (шул исәптән кизү торуларны) ирекле рәвештә башкаруга җәлеп итү турында карар кабул итә һәм аларны үткәрүне оештыра;

- законнар, әлеге Устав, Җирлек Советы карарлары белән Җирлек Советы яки Җирлекнең башка органнарына бирелгән вәкаләтләрдән тыш, җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча башка вәкаләтләрне башкара.

10) муниципаль-хосусый партнерлык өлкәсендә җирлек башкарма комитеты гамәлгә ашыра:

- муниципаль-хосусый партнерлык проектын тормышка ашырганда җирле үзидарә органнары эшчәнлеген килештерүне тәэмин итә;

- ачык партнерга муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү төзү хокукына конкурслар үткәрү өчен конкурс документациясен килештерә;

-муниципаль-хосусый партнерлык турында килешүне тормышка ашыруга күзәтчелек итә;

- муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүне гамәлгә ашыру барышында ачык партнерларның һәм хосусый партнерларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауда булышлык күрсәтә;

- муниципаль-хосусый партнерлык турында төзелгән килешүләр реестрын алып бара;

- муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү турындагы мәгълүматның ачыклыгын һәм һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итә;

- вәкаләтле органга муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүне гамәлгә ашыруны күзәтү нәтиҗәләрен тәкъдим итә;

- “Россия Федерациясендә дәүләт-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турында һәм Россия Федерациясенең аерым законнары актларына үзгәрешләр кертү турында” 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль законда каралган, башка федераль законнар, Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм норматив хокукый актлары, әлеге устав, җирлекнең муниципаль хокукый актлары белән каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. Башкарма комитет Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә карамаган мәсьәләләрен хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

- Җирлек музейларын булдыра;

- Җирлектә нотариус булмаган очракта, законнарда каралган нотариаль гамәлләр кыла;

- опека һәм попечительлек эшчәнлеген тормышка ашыруда катнаша;

- Җирлек территориясендә җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын тормышка ашыру белән бәйле эшчәнлекне башкару өчен шартлар тудыра;

- Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм Җирлек территориясендә милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге чараларны тормышка ашыруга ярдәм итә;

- Җирлек территориясендә урнашкан муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләрнең мобилизация әзерлеге чараларын оештыруда һәм тормышка ашыруда катнаша;

- муниципаль янгын сагы булдыра;

- туризмны үстерү өчен шартлар тудыра;

- кеше хокукларын тәэмин итүгә иҗтимагый контрольлек итүче иҗтимагый күзәтчелек комиссияләренә һәм мәҗбүри тоту урыннарында булган затларга ярдәм күрсәтә;

- «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында»1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук гомумроссия инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре оештырган оешмаларга ярдәм күрсәтә;

- төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тота, күрсәтелгән кагыйдәләргә туры китереп, Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыра.

3. Җирлекнең Башкарма комитеты муниципаль контрольне тормышка ашыруга вәкаләтле орган булып тора.

Муниципаль контроль өлкәсендә Җирлек Башкарма комитеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) тиешле территориядә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру;

2) җирле үзидарә органнарына бирелгән төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру;

3) эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентларын эшләү. Күрсәтелгән административ регламентларны эшләү һәм кабул итү Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла;

4) эшчәнлекнең тиешле өлкәләрендә муниципаль контрольнең нәтиҗәлелеген күзәтеп торуны оештыру һәм үткәрү, аны үткәрү күрсәткечләре һәм методикасы Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана;

5) федераль законнарда, Татарстан Республикасы субъектларының законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

Муниципаль контрольне турыдан-туры гамәлгә ашыру функцияләре Җирлек Башкарма комитеты органнарына әлеге органнарның статусын билгели торган хокукый актлар нигезендә йөкләнә ала.

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру белән бәйле мөнәсәбәтләргә, юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү мөнәсәбәтләренә “Дәүләт контролен һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

**8) 85 статьяны түбәндәге редакциядә бирергә:**

**«1.** Җирлек Советы түбәндәге финанс контроле формаларын гамәлгә ашыра: алдан контроль - бюджет турында карар проектларын тикшерү һәм раслау барышында; агымдагы контроль-Җирлек Советы утырышларында

бюджет үтәлешенең аерым мәсьәләләрен карау барышында; аннан соңгы контроль-бюджет үтәлеше турындагы хисапны карау һәм раслау барышында, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә контрольнең башка формалары.

Җирлек Советы финанс контролен Россия Федерациясе Бюджет Кодексы нигезләмәләренә яраклаштырып гамәлгә ашыра.»

**9) 87 статьяга түбәндәге эчтәлекле 7 өлеш өстәргә:**

«3.1 Җирлек Уставына кертелгән, җирле үзидарә органнары структурасын, җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләр бүленешен үзгәртә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр (җирлек уставын федераль законнарга туры китерү очракларыннан, шулай ук җирле үзидарәнең вәкаләтләрен, сайланулы вазыйфаи затларын сайлау тәртибен үзгәртү очракларыннан тыш) күрсәтелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар кабул иткән Җирлек Советының вәкаләтләре срогы чыкканнан соң үз көченә керә.»

2. Әлеге карарны дәүләт теркәвенә алу өчен, кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә, федераль башкарма хакимиятнең уставларны теркәү өлкәсендә вәкаләтле органының территориаль органына җибәрергә.

3. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Башлыгына «Наласа авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" карарын, федераль башкарма хакимиятнең уставларны теркәү өлкәсендә вәкаләтле органының территориаль органыннан килгәннән соң 7 көн эчендә, халык күп җыела торган урыннарга урнаштыру һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар Рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Арча муниципаль районы Наласа авыл җирлеге Башлыгына үзгәрешләр һәм өстәмәләрне рәсми рәвештә халыкка җиткерү чыганагы һәм датасы турында белешмәләрне, рәсми игълан ителгән көннән алып 10 көн эчендә, федераль башкарма хакимиятнең уставларны теркәү өлкәсендә вәкаләтле органының территориаль органына җибәрергә.

Наласа авыл
җирлеге Башлыгы И.Р.Шакирова

СОВЕТ НАЛАСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ